РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТИХОНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423655 Менделеевский район, с. Тихоново, ул. Шишкина д. 3А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТИХОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423655 Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин урамы, 3А

тел./факс (85549)3-43-62 Email: Tihon.Men@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.07. 2023 ел № 17

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге Советының
карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-09/1230 номерлы аңлатмалары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Тихоново авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында » Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советының 2015 елның 7 апрелендәге 117 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Тихоново авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы  Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советының 2015 елның 7 апрелендәге 118 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга. https://mendeleevsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге Советы рәисе                А. М. Карманов